Нәҗия апа да гел хәер сорамаган. Пермь шәһәренә китеп, заводка эшкә урнашкан. Әни Менделеев шәһәрендә Вафин фамилияле судья гаиләсендә бала да караган әле. Аларның күршесендә яшәүче русларның дуңгызларын югач, марҗа әби аңа килененнән калган аяк киемен бирә. Туганнары да, балалар йортыннан чыгып,



Пермь шәһәренә, Нәҗия апа янына җыелышалар. Авылда яшәргә мөмкинчелек калмагач, әни дә, сыерын сатып, алар янына китә. Сеңлесе Фәлимә апа хакына әни кеше ышанмаслык адымга бара: ул яратмаган кешесенә кияүгә чыга. Бу тарихның шаһитләре инде мәрхүм, язарга була. Үзем бу хакта белгәндә зур идем инде. Әни үз тормышын сөйләргә ярата иде, тыңлап утыручы гына булсын. Безгә гыйбрәт, сабак булсын, дигәндер инде. Теге адәм Фәлимә апаны ФЗОга җибәрми калдыра ала, тик бер шарт- әни аңа кияүгә чыга. Әни, бичара, нишләсен, риза була. Бер татар карчыгы аларга никах укый. Озак та үтми ул кешене армияга алалар. Әниләр, барысы бергә



Мөхәммәтнур абый

җыелышып, Казанга кайталар. Нәҗия апа белән Фәлимә апа гомер буе Казан Компрессорлар заводында эшләделәр. Мөхәммәтнур абый Казан химия-технология институтын тәмамлый. Партиянең райком комитеты секретаре булып, завод директоры булып эшли. Аларга башта тулай торактан бүлмә, аннан соң Нагорный бистәсеннән бер генә бүлмәле фатир бирәләр. Мөхәммәтнур абый башлы-күзле булгач,

гаиләсе белән Дәрвишләр бистәсенә күчеп яши башлый. Алар гаҗәп туган җанлы кешеләр иде. Әтине үлеп яраталар, бер-берсе өчен нишләргә белми торган иделәр. Апаларының 5 баласы да алар кулы аркылы үтте. Исең китәрлек: кеше үз- үзенә ышанмаган заманда, абый белән минем кулда аларның фатир ачкычлары бар иде. Кайчан гына килеп керсәң дә, синең хәлне белешә, тамагыңны кайгырта торган туган иде алар. Фәлимә апа бик оста тегә- чигә. Нәҗия апа пешергән өчпочмакларның тәме әле дә тел очында. Нишләп зур итеп ясый икән ул аларны, дип аптырый идем. Аңладым. Үзләре кечкенә чакта тамаклары туйганчы ашамаган бит алар! Турайдан Казанга килгән кем генә үтмәде икән аларның бер

бүлмәле фатирыннан! Якты чырайлары, ягымлы сүзләре беркемгә дә аларда үзләрен ят, артык итеп тоярга урын калдырмый иде. Тик, тәкъдирләренә шулай язылгандыр инде, апаларыбызга гаилә бәхете татырга язмаган икән. Фәлимә апабыз Гаскәр исемле Турай егетенә кияүгә чыга, тик туганнары аларга тыныч яшәргә бирмиләр. Аерылсалар да, алар барыбер берсен берсе яратканнардыр. Гаскәр абый “Ижминвод” ял йортында шеф- повар булып эшләде. Әти белән бик якын аралашалар иде. Сукыр эчәгесенә операция ясаганда, апаның эчендә тампоннар калдыралар, ул өйгә чыгасы көнне үлә. Фәлимә апага нибары 33 яшь кенә иде. Мин ул көнне бүгенгедәй хәтерлим. Бездә каз өмәсе иде. Әти белән әни Казанга җыенып чыгып киттеләр. Фәлимә апаның үлемен әти фатир ишеге төбенә килеп җиткәч кенә әйтә. Мин апамны соңгы тапкыр больницада күрдем. Мин авырып ятканда, ул минем хәлемне белергә килде. Ул алып килгән алмалар кебек тәмлене гомеремдә башка ашаганым булмады.



Уңнан икенче әни, эти, Фәлимә апа. Бәхетле мизгелләр

1952 елда, 3 ел ярым хезмәт итеп, эти дә авылга кайта. Әти кайтканда ә ... да булмый. Әти ... на сәркәтип ит ... ай эшләгәннән соң, К ... гы институты ка ... ыл хуҗалыгы мәктәбенә укырга җибәрәләр. Әтинең Казанда укыган ... ән Фәлимә апа аны эзләп киләләр. Алар күрешәләр, аңлашалар, бергә булырга сүз куешалар. 1954 елның октябрь аенда ике яшь бергә кушылып яши башлыйлар.

Казанда укыганда эти белән әнинең фотоларын бергә куеп ясаткан идем. Бигрәк матур инде алар.





Авыл хуҗалыгы мәктәбен тәмамлагач, эти читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә һәм аны 1963 елда тәмамлый. Әтинең укыганда язылган конспектлар дәфтәре бар иде. Берничә дәфтәрне берләштереп теккән, һәр юлына

язылган, рәсем- схемалары төрле төсләр белән ясалган шактый калын иде ул. Исем китеп карый идем шул дәфтәрне. Гайшә апаның сорап алганын беләм, кире генә кайтармады. Әти Казанда калыйк, эш тә, торырга урын да табарбыз, дип карый. Тик әни авылны сагына, бер бөртек улы гына булган булачак каенанасын да кызгана. Шулай итеп, алар Турайга кайтып яши башлыйлар. Әти институт тәмамлаганда абый, мин, сеңлебез Гүзәлия инде туганбыз.

Әти гомер буе колхозда хезмәт куйды. Тирән белемле, булдыклы, тәҗрибәле



Артта елмаеп әти утыра, Мөхәммәтнур абый, әни алдында абый, Нажия апа алдында мин, Фәлимә апа

агроном иде. Колхоз рәисе, авыл Советы рәисе булып эшләде. Лаеклы ялга киткәч тә әле аны язгы чәчү вакытында тырма- чәчкечләрне карап, тирәнлекләрен көйләргә чакыра иделәр. Ирләре яу кырында ятып калган толларга өйләр салдырды. Яңа мәктәп бинасы җиткерде. Авылда кирпич заводы сафка басты. Җир сугару системасы эшли иде. Колхозның машина- трактор паркында комбайн, машина, тракторлар солдатлар кебек тезелеп тора иделәр. Ындыр табагы ашлык белән тулы була иде. Борчак покослары шулкадәр калын була, без, бала- чага, үсмерләр аны көбәләргә йөри идек. Агроном балалары булгач, иң элек колхоз эшенә без чаба идек. Без чыкмасак, ничек башка кеше баласы барсын инде ул эшкә. Чөгендер басуында да, амбарда көндез дә, төнге эштә дә, кирпич заводында да эшләргә туры килде. Үткән җәй абый авылның әти белән бәйле урыннарын йөреп чыкты, видеога төшерде, аларны карап, күңел сыкрады. Әти күрсә, кычкырып елар иде. Барны юк итүнең берние дә юк шул. Без бала чакта әтине сирәк күрә идек, бигрәк тә яз, җәй, көз көннәрен. Ул эшкә киткәндә без әле йоклыйбыз, ул кайтканда без инде йоклыйбыз. Ул басу- кырларын җәяүләп күпме тапкырлар узгандыр?! Аңлый башлагач, мин йокламый әтинең эштән кайтканын көтеп ала идем. Көне буе йөреп арыган аякларына массаж ясыйм, бармак араларын дару белән чистартам, чәчләрен тарыйм. Ул рәхәтләнеп ял итә. Мин- әти

кызы булып үстем. Ике генә яшькә олы абыем, мине больницадан алып кайткач, “айт-два бәбәегезне үтерәм. Мин алдан килдем, әни минеке,”- ди торган булган. Әни мине ашатып әтигә биргән, мин әти кочагында үскән бала. Бәлки, шуңа күрәдер, без бер-беребезне яхшы тоя, аңлый идек. Хәбәр итми генә кайтып килгәндә дә, автобус тукталышында көтеп торган чагы булыр иде.

Ә әни...әни гомерен әтигә, балаларга багышлады. Башта балалар бакчасында, аннан соң, поварлар курсын тәмамлап, мәктәптә повар булып эшләде. Интернатта торып укучы Ахтыял балалары да, үзе дә аларны бик ярата иде. Рифкатькә бик рәхмәтле булды. “Мин үлгәч, озатырга килерсең”,- дигәнен белгәч, мин Рифкатьне әнине соңгы юлга озатырга чакырдым, рәхмәт, килде. Әти белән әнинең безне тәрбияләп утырырга вакытлары булмаган. “Оясында ни күрсә, очканында шул була”, дип белми әйтмәгәннәр. Әти агроном булып эшләсә дә, кесәсенә бер уч ашлык та салып кайтмый торган иде. Мине утыртып куйсалар, минем 5 балам нишләр, ди торган булган. Шулай да, мин безнең өйгә тентү белән килгәннәрен хәтерлим. Аллага шөкер, барыбыз да үз көчебез белән яшәргә өйрәндек, кешенең шырпысына да кагылганыбыз юк. Без биш баланы әтине яратырга, олыны хөрмәт итәргә ул өйрәтте. Әтинең ятып ял иткән вакыты буламы, авырган вакытымы- өйдә тынлык була иде, без аяк очына гына басып йөри идек. Утын кискән, печән чапкан, өйдә хатын -кызның тавык чүпләп бетми торган эш- барысын да әни эшләгән. Без кул астына иртә кердек: өй җыештыру, кер чайкау, су ташу, өй тирәсендәге башка вак- төяк эш  безнең өстә иде. Әти сәламәтлеккә туймады. Ашказанындагы язвасы тынгы бирмәде. Менделеевск больницасында әнине белмәгән, аңа сокланмаган врач, медсестра булмагандыр.  Үзе турында онытып, әтине кадерләде. 50 яшькә кадәр яшәп булмас, дип әтинең 40 яшен билгеләп үттеләр. Әнинең бер шәп ягын әйтми булмый: ул әти хакына утка да, суга да керергә әзер иде. Әни барында бер генә кеше дә әтигә җайлы-җайсыз сүз әйтергә базмагандыр. Инде, ялгыш ычкындыра калса, минуты белән әнидән җавабын ала, ник әйткәненә үкенерлек итә иде. Мин андый вакыйганы берне генә беләм. Тик әни кебек итеп сөйли алмам дип куркам, шуңа күрә генә язмыйм.